ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ТОЙГУҖА АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

«28» ноябрь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлегендә гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 118 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2023 елның 28 ноябрендә 14.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?” дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде

- скважина өчен су насосы сатып алу;
- суүткәргеч бикне һәм янгын гидрантларын комплектта сатып алу;
- суүткәргеч бикне һәм янгын гидрантлары урнаштыру;
- авыл җирлеге территориясендә үлән чабу;
- юлларны кардан чистарту;
- узган елларның калдыкларын янгын гидрантларын урнаштыруга җибәрергә».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 100 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 60 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 60 граждан тавыш бирде; "ЮК" - 0 граждан;“ТЫЕЛЫП КАЛДЫ” - 0 граждан

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?” дигән сорау каралган дип санарга:

- скважина өчен су насосы сатып алу;
- суүткәргеч бикне һәм янгын гидрантларын комплектта сатып алу;
- суүткәргеч бикне һәм янгын гидрантлары урнаштыру;
- авыл җирлеге территориясендә үлән чабу;
- юлларны кардан чистарту;
- узган елларның калдыкларын янгын гидрантларын урнаштыруга җибәрергә».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А.Сафин